сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм аларга ия булырга, акчалата һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларын белергә һәм (яки) кулланырга тыю турында»,2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон, әгәр әлеге Федераль законда башкасы каралмаган булса.»;

7) 28 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип санарга;

8) 38 статьяның 3 пунктындагы 1 пунктчасында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары »сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 43 статьяның 2 пунктындагы 11 пунктчасын үз көчен югалткан дип санарга;

10) 6 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасын «күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту чаралары» сүзләрен «хуҗасыз хайваннар, яшәүчеләр белән эш итү эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

11) 43 статьяның 2 пунктындагы 13 пунктчасын «күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту чаралары» сүзләрен « хуҗасыз хайваннар ,яшәүчеләр белән эш итү эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

12) киләсе эчтәлекле 40.1 статьялар өстәргә:

**«40.1 Статья. Авыл Җирлеге Башлыгы Урынбасары**

1. Авыл җирлеге Башлыгы тәкъдиме белән Җирлек Советы тарафыннан депутатлар арасыннан Җирлек Башлыгы урынбасары сайлана.

2. Җирлек Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыгы тавыш бирсә, Җирлек Башлыгының сайланган урынбасары дип санала.

3. Җирлек Башлыгы урынбасары вазыйфаларны җирлек Советы Регламентында билгеләнгән бурычларны бүлү нигезендә башкара, Җирлек Башлыгы йөкләмәсен үти, ә вакытлыча (авыру яки отпускка китү сәбәпле) яки үз вазыйфаларын башкара алмаган очракта, яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Җирлек Башлыгы вазыйфаларын башкара.

4. Җирлек Башлыгы урынбасары үз вәкаләтләрен бушатылмаган нигездә башкара.

5. Җирлек Башлыгы урынбасарының вәкаләтләре әлеге Уставның 39 статьясында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла.

6. Җирлек Башлыгы урынбасары, җирлек Советы карары белән, җирлек башлыгы инициативасы белән кабул ителгән яки җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бер өлеше булган депутатлар төркеме таләбе буенча, теләсә кайсы вакытта да вазифасыннан чакыртып алынырга мөмкин. Җирлек Башлыгы урынбасарын чакыртып алу турындагы карар Җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.».